ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНЭ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы., 422528

**КАРАР**

2019 елның 22 январы №1

Рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан тайпылышка рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Бишнә авыл җирлеге Советының 15.01.2013 ел, №98 карары белән расланган Бишнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә (Бишнә авыл җирлеге Советының 07.07.2017 ел, №115 карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2018 елның 23.11.2018 гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча

Карар бирәм:

1. Рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан тайпылу өчен рөхсәт бирергә:
- Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Бишнә авылы, Тынычлык урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан 16:20:070101:67 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен, минималь араны көнбатыш ягыннан 3 метрдан 1,5 метрга кадәр киметү өлешендә, көнчыгыш яктан 3 метрдан 1,2 метрга кадәр өлешендә;
- Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Берновые Кавали авылы, Үзәк урамы, 58 йорт адресы буенча урнашкан 16:20:070301:90 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен, минималь араны төньяктан торак йортка кадәр 3 метрдан 2 метрга кадәр, көнчыгыш яктан 3 метрдан 0,8 метрга кадәр, көньяк ягыннан 3 метрдан 1,2 метрга кадәр киметү өлешендә;
- Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Рус-Мари Кавалы авылы, Үзәк урамы, 25 нче йорт адресы буенча урнашкан 16:20:070201:58 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен, участок чигеннән алып төньяктан 2 метрдан 2 метрга кадәр минималь араны киметү өлешендә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**